**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXI УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 41**

Баланлы ав. 29 август 2022 ел.

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 08 ноябрендәге № 1 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә юл сервисы объектлары урнашкан территорияләрне барлау һәм җыештыруны тикшереп тору, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карар проекты буенча ачык тыңлау нәтиҗәләре турында бәяләмә, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 19.07.2022 елгы 01-16/5057 номерлы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 08 ноябрендәге №1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«III. Алар урнашкан биналарны, корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен тышкы күренешенә, фасадларның һәм коймаларның, юлларның, индивидуаль торак йортларның, яңгыр канализациясе челтәрләренең, күзәтү һәм яңгыр сулары коеларының, су бүлеп чыгару корылмаларының, техник элемтә чараларының, тышкы яктырту объектларының, кече архитектура формаларының, стационар булмаган объектларның, төзелеш эшләрен җитештерү урыннарының, күмү урыннарының тышкы кыяфәтенә, автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннарына карата таләпләр. Авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү. «Юл сервисы объектлары».

-- III бүлекне «Сервис объектларын карап тоту» өлеше һәм киләсе эчтәлектәге пунктлары белән тулыландырырга 77/1.1, 77/1.2, 77/1.3:

«Сервис объектларын карап тоту»

77/1.1. Сервис объектлары территорияләрен карап тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

77/1.2 Юл буе сервисы объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- уңайлы хәрәкәт итү өчен каты түшәмә;
- территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;

- аларны урнаштыру һәм карап тоту таләпләрен үтәп бәдрәф кабиналары;

- чүп савытлары һәм чүп өчен кечкенә контейнерлар;

- яшелләндерү (газоннар, чәчәклекләр) һәм яшелләндерү участокларын саклау элементлары (киртәләр).

77/1.3. Сервис объектларын урнаштыруга, аларны һәм аларга якын территорияләрне карап тотуга таләпләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- керү-чыгу урыннарында, сервис объектларына керү юлларында күчеш-тизлек полосалары булырга тиеш;

- күчеш-тизлек полосаларында һәм сервис объектлары территорияләрендә тышкы яктырту булырга тиеш;

- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына бару юллары, гамәлдәге сууткәргеч системасы белән бәйле (съездлар астына сууткәргеч торбалар тутырылырга тиеш) озынча сууткәргеч торбалар тәэмин ителерлек итеп төзекләндерелергә тиеш;

хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының һәм аңа төшү юлларының буй авышлыгы юлдан капма-каршы якка юнәлтелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиусы чикләрендә ул 20% тәшкил итәргә тиеш.

- мәйданчыкта һәм аңа төшү юлларында автомобиль юлы белән тигез дәрәҗәдәге камилләштерелгән каты түшәмә булырга тиеш;

- «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары» ГОСТ Р 52289-2019 таләпләре нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары булу. Юл билгеләрен, тамгаларны, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш бирү җайланмаларын куллану кагыйдәләре;

Сервис объекты территориясендә эксплуатация һәм карап тоту барышында дефектларны бетерү ГОСТ Р 59292-2021 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары» таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Җәй көне карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» һәм ГОСТ Р 59434-2021 Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кыш көне карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары».

- функциональ билгеләнеше буенча хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә шул исәптән санитар-гигиена зонасы булырга тиеш;

- тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан тәртиптә булырга һәм бирелгән техник шартлар нигезендә эксплуатацияләнергә тиеш;

- юл буе сервисы объектларының транспорт чараларын вакытлыча кую урынында (стоянкасында) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен урыннар бирелергә тиеш»;

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендта Баланлы авыл җирлеге битендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http://muslumovo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән уз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баланлы авыл җирлеге
башлык урынбасары: Г.Ф.Юнусова